**Республика Татарстан**
**Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

05.04.2023 г.

№ 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман районы Прокуратурасы 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүмат, Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының 2020 елның 10 июнендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 пунктның 1,3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

е) 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Н.Камалетдинов